**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**18.03.2022 ел** **№ 332**

2022 елда Биектау муниципаль районы территориясендә язгы ташу чорында биналарның, күперләрнең, автомобиль юлларының, гидротехник корылмаларның, торак фондының, башка матди кыйммәтләрнең сакланышын һәм кешеләрнең гомерен саклауны тәэмин итү турында

Язгы ташу чорында биналарның, автомобиль юлларының, күперләрнең, гидротехник һәм башка корылмаларның сакланышын тәэмин итү максатларында Биектау муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Су басуга каршы район комиссиясен кушымта нигезендә расларга.
2. Хуҗалыклар, предприятиеләр җитәкчеләренә, авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- районның авыл җирлекләрендә, хуҗалык субъектларында язгы ташуга каршы комиссияләр булдырырга;
- су басу күздә тотылган зоналардан барлык булган матди кыйммәтләрне үз вакытында чыгаруны тәэмин итәргә, шулай ук язгы ташу вакытында авария, коткару һәм башка ашыгыч эшләрне башкару өчен билгеләнгән материаль ресурсларның кирәкле запасларын әзерләргә;
- ташу суларының югары дәрәҗәдә булуы күздә тотылган зоналарга даими контроль урнаштырырга; буаларда кизү торуны оештырырга, югары су күтәрелү чорында предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә җаваплы хезмәткәрләрнең тәүлек буе кизү торуын билгеләргә;
- биналарны һәм корылмаларны, склад һәм башка биналарны су басуны, матди кыйммәтләрне, шулай ук автомобиль юлларын һәм күперләрне зыян күрүен кисәтә торган кичектергесез чаралар үткәрүгә аерым игътибар биреп, язгы ташуга әзерлек чараларын эшләргә һәм аларның үтәлешенә даими контроль оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Биектау районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Р.З. Кәримовка, хуҗалыклар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- буаларда язгы ташуга әзерлек буенча үз вакытында чаралар күрергә һәм сугару системаларының һәм су сиптерү җайланмаларының сакланышын тәэмин итәргә;
- агулы химикатларны һәм башка пычраткыч матдәләрнең юылуын булдырмау буенча үз вакытында чаралар күрергә.

4. Авыл җирлекләре башлыкларына Биектау муниципаль районы башкарма комитетына (Биектау муниципаль районы ЕДДС) үзләренә ышанып тапшырылган территориядәге вәзгыять һәм язгы ташуга әзерлек буенча күрелә торган чаралар турында мәгълүмат бирергә тәкъдим итәргә.

5. Түбәндәге выл җирлекләре башлыкларына: Усад - Ф.А. Зәбировка, Бөреле – Т.Х. Баһаветдиновка, Дачный – А.М. Дәүләтшинга, Чыпчык - И.Р. Җиһаншинга тәкъдим итәргә:

- коткару чараларын әзерләргә һәм аларны урнаштыру урыннарын билгеләргә;
- язгы ташу вакытында кичектергесез эшләрне башкару өчен кирәкле матди ресурсларның запасларын әзерләргә.

6. Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (Вәлиуллина Р.Ш.) кирәк булганда язгы ташуга каршы чараларга, Биектау муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе гаризасы буенча акча бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

7. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «2021 елда Биектау муниципаль районы территориясендә язгы ташу чорында биналарның, күперләрнең, автомобиль юлларының, гидротехник корылмаларның, торак фондының, башка матди кыйммәтләрнең сакланышын һәм кешеләрнең гомерен саклауны тәэмин итү турында» 2021 елның 11 февралендәге 194 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Д.Ф. Шәйдуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
18.03.2022 №332 нче
номерлы карарына кушымта

Биектау муниципаль районының су басуга каршы
район комиссиясе составы (килештерү буенча)

| № т/б | Вазыйфа | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефоны эш, йорт, кәрәзле |
|---|---|---|---|
| 1. | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары | Хәкимуллин Рамил Фатыйх улы | эш. 2-30-58, к. 89274848477 |
| 2. | Биектау муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе | Афанасьев Алексей Павлович | э. 2-40-50, к. 89196825197 |
| 3. | Биектау янгын сүндерү-коткару гарнизоны башлыгы | Шәймәрдәнов Раил Рөстәм улы | э. 3-10-68, к.89196261111 |
| 4. | ТР ГТХМ гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты (Биектау муниципаль районы буенча) | Ковтун Владимир Анатольевич | э. 3-10-68, к. 89061136231 |
| 5. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча бүлеге башлыгы | Вәлиев Айнур Зиннур улы | э. 2-40-00 к. 89997580116 |
| 6. | «Биектау РҮХ» ДАССУ баш табибе | Зиатдинов Рамил Равил улы | э. 2-33-43 к. 89172737230 |
| 7. | Биектау районындагы Роспотребнадзор идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы | Салкова Эльвира Валентиновна | э. 3-02-71, к. 89053108917 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 8. | Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы | Хөснетдинов Артур Мифтахетдин улы | э. 2-30-68,<br>к. 89272420408 |
| 9. | Биектау РУЭС башлыгы | Әдһәмов Айрат Ислам улы | э. 2-30-00,<br>к. 89179269913 |
| 10. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Биектау районы буенча идарәсе башлыгы | Кәримов Рәхимҗан Зариф улы | э. 2-36-80,<br>к.88432267101 |
| 11. | Биектау РЭСы башлыгы, энергетика һәм яктылык маскировкасы хезмәте башлыгы | Гыйниятуллин Марат Наил улы | э. 3-11-85,<br>к. 89872908121 |